КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 26 ноябрь г.Казань № 1004

2025 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган программалары һәм өстәмә гомуми үсеш бирүче программалар буенча мәгариф эшчәнлеге тора торган бүлекчәсе булган югары белем бирүче мәгариф оешмасына ярдәм итү» грантын бирү турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2025 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган программалары һәм өстәмә гомуми үсеш бирүче программалар буенча мәгариф эшчәнлеге тора торган бүлекчәсе булган югары белем бирүче мәгариф оешмасына ярдәм итү» грантын бирү турында нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре

булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү» гранты һәм аны бирү тәртибе турында» 2021 ел, 13 август, 721 нче карары гамәлен 2026 елның 1 гыйнварына кадәр  гамәлдә булуын туктатып торырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 26 ноябрь, 1004 нче карары белән расланды

2025 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган программалары һәм өстәмә гомуми үсеш бирүче программалар буенча мәгариф эшчәнлеге тора торган бүлекчәсе булган югары белем бирүче мәгариф оешмасына ярдәм итү» грантын бирү турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «««Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Рәисенең «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенә грант ярдәме турында" 2025 елның 12 сентябрендәге 720 номерлы Указы нигезендә эшләнде һәм «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия формасында грант (алга таба – грант) бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

2. Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак 2025 елда грант бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Грант Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә

яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган программалары һәм өстәмә гомуми үсеш бирүче программалар буенча мәгариф эшчәнлеге тора торган бүлекчәсе булган югары белем бирүче мәгариф оешмасына ярдәм итү белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатларында бирелә.

Бирелә торган грантның күләме 31 972,1 мең сум тәшкил итә.

Грант бирү алымы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

4. Грант алучы – «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (алга таба – Алучы).

5. Грант турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба шул ук эзлеклелектә – бердәм портал, «Интернет» челтәре) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

6. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

салымнар һәм җыемнар турында Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

мәктәпкәчә белем бирү программаларын, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган программаларын һәм өстәмә гомуми үсеш бирүче программаларны аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында гамәлгә ашыру белән бәйле хезмәткәрләрнең хезмәт хакын түләү, бүлекчәдә аутистик спектры бозылган балаларны тәрбияләүче гаиләләргә консультатив-диагностик ярдәм күрсәтү өлешендә .

бүлекчәне карап тоту;

бүлекчәнең эшләве өчен ашыру өчен кирәкле уеннар, уенчыклар, уку пособиеләре сатып алу.

7. Заявканы карап тикшерү датасына карата Алучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия

юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;https://internet.garant.ru/document/redirect/404991865/0

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмау яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (Алучыга башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, Алучыга карата банкротлык процессы билгеләнми, Алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмый;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер кеше башкара торган башкарма орган функциясен үтәүче зат яки Алучының баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмый.

8. Грант алу өчен Алучы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендә форма буенча Алучы турында мәгълүматны «Интернет» челтәрендә бастырып чыгару (урнаштыру) өчен ризалыкны үз эченә алган заявка;

Алучы уставының гамәлдәге редакциясе күчермәсе;

мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары буенча эшчәнлек башкаруга лицензия күчермәсе;

Алучының штат расписаниесе күчермәсе;

аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программасы күчермәсе;

мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган Алучы бүлекчә турында нигезләмә булу;

аутистик спектры бозылган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыру өчен матди-техник тәэминат исемлеге;

мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган белем бирү программасы гамәлгә ашырыла торган бүлмәләрнең булуын раслаучы документларның күчермәләре һәм алардан файдалану хокукы;

Алушы тарафыннан эшләнгән аутистик спектр бозулары булган балаларны укыту методикалары һәм технологияләре турында мәгълүмат;

әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә Алучының туры килүен раслый торган Алучының җитәкчесе (вәкаләтле заты) һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган мәгълүмати белешмә кәгазе.

9. Министрлык:

Алучының заявкасын кергән көнендә документлар әйләнеше кагыйдәләре нигезендә терки;

заявка теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Алучының заявкасын тикшерә һәм тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә һәм грант бирү турында яки грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Грант бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

Алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү.

Грант бирүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Министрлык Алучыга, грант бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәрнамә җибәрә һәм Алучыга тапшырылган документларны грант бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә кире кайтара.

11. Грант бирү нигезе – Министрлык белән Алучы арасында төзелә торган грант бирү турында килешү (алга таба – килешү). Килешү грант бирү турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелә.

Килешүдә Министрлык һәм Алучы арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзү шартлары һәм тәртибе булырга тиеш.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

Алучының, шулай ук Алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы;

килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шартлар.

12. Алучы кушылу, кушу яки үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук Алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, Алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган йөкләмәләр һәм грантның файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

13. Алучыга, шулай ук Алучы белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы башка юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлаучы әйберләр сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела.

14. Грант бирү нәтиҗәләре:

көн саен 5,5 сәгать дәвамлылыгы белән көн саен гамәлдә булган, даими рәвештә 2025 ел дәвамында кыска вакытлы 10 төркемдә була торган аутистик спектр тайпылышлары булган мәктәпкәчә яшьтәге 50 баланы укытуны тормышка ашыру (һәр кыска вакытлы төркемдә балалар саны кимендә биш кеше тәшкил итә);

даими рәвештә консультацион-диагностик озату алучы аутистик спектр бозулары булган кимендә 70 бала өчен консультацияләр үткәрү.

Грант бирү нәтиҗәләренә 2025 елның 31 декабреннән соңга калмый ирешелергә тиеш.

15. Грант килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Алучы тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерелә.

16. Алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча грант бирү нәтиҗәләре күрсәткеченә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

Министрлык әлеге пункт нигезендә тапшырылган хисапларны әлеге хисаплар тапшырылган көннән алып 10 эш көненнән артмаган срок эчендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

17. Министрлык Алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне башкара.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәгә ирешүне мониторинглау тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.

18. Бирелгән грант, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган грант бирү шартлары Алучы тарафыннан бозылган очракта, шулай ук грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

19. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган акчаның хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше, 2026 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә кире кайтарылырга тиеш.

20. Әлеге Нигезләмәнең 18 һәм 19 пунктларында күрсәтелгән акча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә ирекле рәвештә кире кайтарылудан баш тартылган очракта, алар Министрлык тарафыннан эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

2025 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган программалары һәм өстәмә гомуми үсеш бирүче программалар буенча мәгариф эшчәнлеге тора торган бүлекчәсе булган югары белем бирүче мәгариф оешмасына ярдәм итү» грантын бирү турында нигезләмәгә кушымта

Форма

2025 елда «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган мәгариф программалары һәм өстәмә гомуми үстерү программалары буенча мәгариф эшчәнлеге торган бүлекчәсе булган югары белем бирү мәгариф оешмасына ярдәм күрсәтү» грантын алуга заявка

«___»__________ 2025 ел

1. Юридик затның тулы исеме: ____________________________________________________________________________________________ (алга таба - Мөрәҗәгать итүче)

2. Юридик затның кыскартылган исеме: ________________________________.

3. Юридик затны дәүләт теркәвенә алу датасы: ____________________________.

4. Субсидия суммасы: ____________________________________________________.

5. Юридик затның урнашкан урыны: ________________________________.

6. Юридик затның почта адресы: ______________________________.

7. Юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы: _____________________________________________.

8. Субсидия күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында мәгълүмат: ___________________________________________________.

9. Җитәкче, субсидия бирү турында килешүгә имза куярга вәкаләтле зат турында мәгълүмат (Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)), вазыйфасы: ______________________________________________________________________________.

10. Юридик зат гамәлгә кую документлары нигезендә гамәлгә ашырырга хокуклы эшчәнлекнең төп һәм өстәмә төрләре исемлеге: ______________________________________________________________________________.

11. Субсидия бирү нәтиҗәләренең тәкъдим ителә торган күрсәткечләре: ______ ______________________________________________________________________________ ______________________________________________________________________________ __________________________.

Әлеге гариза белән Гариза бирүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2025 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган программалары һәм өстәмә гомуми үсеш бирүче программалар буенча мәгариф эшчәнлеге тора торган бүлекчәсе булган югары белем бирүче мәгариф оешмасына ярдәм итү» грантын бирү турында нигезләмәне раслау хакында" 2025 ел, 26 ноябрь, 1004 нче карары белән расланган 2025 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, үз структурасында төп эшчәнлек төре булып аутистик спектры бозылган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерүнең махсус булдырылган шартларында мәктәпкәчә белем бирү программалары, мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган программалары һәм өстәмә гомуми үсеш бирүче программалар буенча мәгариф эшчәнлеге тора торган бүлекчәсе булган югары белем бирүче мәгариф оешмасына ярдәм итү» грантын бирү турында нигезләмәнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый.

Әлеге гариза белән Гариза бирүче «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Гариза бирүче турында, бирелә торган гариза турында мәгълүмат, әлеге Нигезләмәгә бәйле Гариза бирүче турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгымны бирәм.

Кушымталар: 1.
2.

Җитәкче_______________________________ / ___________________
(Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) (имза)

______________________________